**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлегенең Дружба авылы торак пунктында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

**“12” ноябрь 2020 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 12 ноябрендә 14.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2021 елда 300 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлардан; хәрби хезмәт үтүче гражданнардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

1) Дружба авылы очен янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру;

2) Ләке авыл җирлегенең Дружба авылындагы өлкәннәр һәм инвалидлар көнен үткәрү өчен бүләк пакетлары сатып алу

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 36 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 28 кеше кертелгән.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::
җыенда 28 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:
1. Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Дружба торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танылды.
2. "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Дружба торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I төркем инвалидларыннан, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, сез 2021 елда үзара салым кертергә ризамы?:
1) Дружба авылы очен янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру;
2) Ләке авыл җирлегенең Дружба авылындагы өлкәннәр һәм инвалидлар көнен үткәрү өчен бүләк пакетлары сатып алу кабул ителде.
3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Ләке авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми

сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче Л. И. Шәрипова